**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023елның 23 июне № 890

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елга Кама Тамагы муниципаль районы халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында» 2022 елның 28 декабрендәге1441 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 маддәләре, «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеген раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының «Гражданнар тарафыннан 2022 елның 26 ноябрендәге ПУ-832 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүләрнең күләмен 2022 елның декабренә һәм 2023 елга үзгәртүнең иң чик (максималь) индекслары турында» Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елга Кама Тамагы муниципаль районы халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында» 2022 елның 28 декабрендәге 1441 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә,әлеге карарга кушымта нигезендә бирергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (инфраструктур үсеш, төзекләндерү һәм ТКХ буенча) Р.Р. Баржановка йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елга Кама Тамагы муниципаль районы халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында» 2022 елның 28 декабрендәге1441 номерлы карарына (23.06.2023 № 890 карары редакциясендә)

# 2023 елга торак хезмәтләренә тарифлар

| № т/б | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Куйбышев Затоны штп 01.01.2023ел. | Куйбышев Затоны штп 01.07.2023ел | Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы 01.01.2023ел | Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы 01.07.2023ел | Тенишево поселогы 01.01.2023ел | Тенеш штп 01.07.2023ел | Авыл |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 1 | 2 | 3 | | | |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 3,72 | 3,84 | 3,70 | 3,88 | 3,70 | 3,88 | - |
| 2. | Торак бинаны ремонтлау, территорияне төзекләндерү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 4,31 | 4,44 | 3,49 | 3,66 | 3,49 | 3,66 | - |
| 3. | Йорт эчендәге инженерлык канализация челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 2,89 | 2,90 | 2,39 | 2,48 | 2,39 | 2,48 | - |
| | Йорт эчендәге су үткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 2,89 | 2,90 | 2,39 | 2,48 | 2,39 | 2,48 | - |
| 4. | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 1,23 | 1,25 | 1,22 | 1,27 | 1,22 | 1,27 | - |
| 5. | Алган өчен түләү (яллаучылар өчен) | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 6,38 | 6,38 | 6,38 | 6,38 | 6,38 | 6,38 | - |
| 6. | Газ белән тәэмин итүнең йорт эчендәге челтәрләренә хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,50 | 0,51 | 0,24 | 0,25 | 0,24 | 0,25 | - |
| 7. | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,25 | 0,26 | 0,25 | 0,26 | 0,25 | 0,26 | - |
| | Төтенлекләргә техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | хезмәт күрсәтелгән булса, аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,95 | 1,0 | 0,95 | 1,0 | 0,95 | 1,0 | - |
| 8. | домофоннарга техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,55 | 0,55 | 0,55 | 0,55 | 0,55 | 0,55 | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Йорт яны территориясен тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 3,44 | 3,55 | 3,34 | 3,58 | 3,34 | 3,58 | - |
| 10. | Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | аена бер кешедән | 59,51 | 59,51 | 59,51 | 59,51 | 59,51 | 59,51 | - |
| 11. | Контейнер мәйданчыкларын тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,11 | 0,11 | 0,11 | 0,11 | 0,11 | 0,11 | - |
| 12. | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 2,88 | 3,00 | 2,88 | 3,0 | 2,88 | 3,0 | - |
| 13. | Дератизация | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0.40 | 0.45 | 0.31 | 0.33 | 0.31 | 0.33 | - |
| 14. | Дезинсекция | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,11 | 0,11 | 0,11 | 0,11 | 0,11 | 0,11 | - |
| 15. | Үзәк җылыту челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 2,63 | 2,63 | - | - | - | - | - |